# КАРАР

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Ялкын авыл җирлеге составына керүче Ялкын авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

14 ноябрь 2019 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 елның 13 ноябрендә «2020 елда Ялкын авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле мәсәләләрне хәл итүгә :

- контейнер мәйданчыклары урнаштыру ;
-җирлек эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау;
-балалар уен мәйданчыгын төзекләндерү;
- торак пунктларның урамнарын карап тоту һәм төзекләндерү.

ӘЙЕ КАРШЫ”

тоту белән килешәсезме? " мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре нигезендә беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 210 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 113 кеше .

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде::

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 113 кеше тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1.Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Ялкын авыл җирлеге составына керүче Ялкын авылындагы гражданнар җыены нәтиҗәләрен-вәкаләтле дип танырга.

2. “2020 елда Ялкын авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 Төркем инвалидларыннан, көндезге бүлектә укучы блеге студентлардан, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны жирле мәсәләләрне хәл итүгә

- контейнер мәйданчыклары урнаштыру ;
-жирлек эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау;
- балалар уен мәйданчыгын төзекләндерү;

- торак пунктларның урамнарын карап тоту һәм төзекләндерү. ӘЙЕ КАРШЫ"

тоту белән килешәсезме? " мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип санарга.

3. Әлеге карарны Ялкын авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Ялкын авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Ялкын авыл җирлеге башлыгы И.В.Гущина